**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**2 нче сентябрь 2016 ел** **№ 67**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 мартындагы 245 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр туктатылган очракта, 35 статьясындагы 16 өлешенең җиденче абзацында, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьясындагы 6.1 өлешендә, 7.1 өлешендә, 10 өлешенең 5 - 8 пунктларында, 40 статьясындагы 10.1 өлешендә, 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча түләнми «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.)

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.А.Гатауллин**